| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 12 ноябре №59**

**Лениногорск муниципаль районының 2019 елга һәм планлы 2020-2021 елларга социаль-икътисадый үсеше буенча фаразы турында**

“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары З.Г.Михайлованың “Лениногорск муниципаль районының 2019 елга һәм планлы 2020-2021 елларга социаль-икътисадый үсеше буенча фаразы турында” мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районының 2019 елга һәм планлы 2020-2021 елларга социаль-икътисадый үсеше буенча фаразының төп күрсәткечләрен 1нче кушымта нигезендә расларга.

2. “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә, тырышлыкны районның социаль-икътисадый үсешенең кичектергесез бурычларын үтәүгә, халыкның яшәү шартларын яхшыртуга юнәлдерергә.

3. Җирле үзидарә органнарына, барлык төр предприятиеләргә финанс-производство эшчәнлекләрен 2019 елгы һәм планлы 2020-2021 еллардагы

социаль-икътисадый үсеше буенча фараз күрсәткечләрен нигез итеп алырга, 1нче кушымта нигезендә.

4.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль пайоны рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар белән контрольлек итүне муниципаль район Советының бюджет, салым һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

“Лениногорск муниципаль районы”

муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Г. Хөсәенов